ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**04.03.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 441**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 12 мартындагы «Зеленодольск муниципаль районы өстәмә белем бирүнең муниципаль бюджет учреждениеләре күрсәтә торган түләүле хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 623 номерлы карарына өстәмәләр кертү хакында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 4 пункты нигезендә һәм 2021 елның 8 февралендәге Зеленодольск муниципаль районының муниципаль предприятиеләре һәм оешмалары хезмәтләренә тарифлар (бәяләр) билгеләү өлешендә тарифларны (бәяләрне) карау комиссиясе карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 12 мартындагы «Зеленодольск муниципаль районы өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениеләре күрсәтә торган түләүле хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 623 номерлы карарының 2 нче кушымтасын 9-21 пунктлар белән, кушымта нигезендә, тулыландырырга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 16 февралендәге «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 12 мартындагы «Зеленодольск муниципаль районы өстәмә белем бирүнең муниципаль бюджет учреждениеләре күрсәтә торган түләүле хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 623 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 304 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. ЗМР Советы аппаратының ММЧ бүлеге начальнигы Р. З. Хаҗиевка әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга .

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.В.Лулаковка йөкләргә.

Җитәкче И. Р. Ганиев

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
кушымта
04.03.2021 №441

**«Зеленодольск муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтүгә хезмәтләр һәм тарифлар исемлеге**

| **№** | **Хезмәтнең исеме** | Үлчәү берәмлеге | **Бәясе-сум.** |
|---|---|---|---|
| 9 | "Китаплар тарихы" мастер-класс | сум/кеше | 100,00 |
| 10 | "Квест" | сум/кеше | 30,00 |
| 11 | Китапханәдә интерактив программа | сум/кеше | 100,00 |
| 12 | "Туган көн китап белән" анимацион программа | сум/кеше | 150,00 |
| 13 | Семинарлар үткәрү өчен бина бирү<br>( № 30 филиал залы 113 кв. м) | сум/сәгать | 500,00 |
| 14 | Семинарлар үткәрү өчен бина бирү<br>(үзәк китапханә залы 94,5 кв. м) | сум/сәгать | 400,00 |
| 15 | Документларны лазер принтерендә төсле<br>А4 форматында бастырып чыгару | сум/ 1 бит | 10,00 |
| 16 | Компьютерда мөстәкыйль эш (өлкәннәр) | сум/сәгать | 40,00 |
| 17 | Мөстәкыйль эш компьютерда (балалар) | сум/сәгать | 30,00 |
| 18 | Документларны лазер принтерендә аклы-каралы<br>А4 форматында бастырып чыгару | сум/ 1 бит | 4,00 |
| 19 | Ихтыяҗ зур булган әдәбият бирү | сум/кеше | 15,00 |
| 20 | Текстны электрон рәвештә җыю | сум/ 1 бит | 20,00 |
| 21 | Текстны үзгәртү | сум/ 1 бит | 10,00 |